ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО АЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ИБЫНДАГЫПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » 01 2025г. № 3

2025 елга Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы «шәһәр тибындагы
Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында"гы 23.01.2025 ел № 33 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, шәһәр тибындагы Урыссу бистәсенең башкарма комитеты к а р а р  б и р ә:

1. 2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә әлеге карарның 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымтасы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген 9 165,00 сум күләмендә билгеләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» Башкарма комитетының 2024 елның 26 гыйнварындагы «2024 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы

Урыссу бистәсе»ндә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегә буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 5 санлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Н. Захаров

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
«шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе»
Башкарма комитетының
2025 елның «30» 01
3 санлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны биреп тору һәм китерү | 3663,93 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 1119,90 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4381,54 |
| Барлыгы | 9165,37 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
«шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе»
Башкарма комитетының
2025 елның «30» 01
3 санлы карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 850,38 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны биреп тору һәм китерү | 2813,70 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 1119,92 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4381,37 |
| Барлыгы | 9165,37 |